МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.03.2016 Казань №01-02/90

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгында
норматив хокукый актларга
һәм норматив хокукый актлар
проектларына коррупциягә каршы
экспертиза уздыру турында

2009 елның 17 июлендәге “Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” № 172-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге “Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” № 96 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге “Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” № 883 номерлы карары нигезендә, **боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының норматив хокукый актлары һәм норматив хокукый актлар проектлары, шулай ук Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан эшләнелә торган норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибен расларга (кушымта).

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны министрның беренче урынбасары Р.И.Заһидуллинга йөкләргә.

Министр в.б. М.М.Ибәтов

Татарстан Республикасы юстиция министрының
2016 елдагы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының (алга таба – Министрлык) норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына (алга таба – актлар, актлар проектлары), шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының Министрлык тарафыннан эшләнелә торган норматив хокукый актлары проектларына (алга таба – эшләнелә торган акт проекты) коррупциягә каршы экспертиза үткәрү процедурасын билгели.

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүнең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең коррупциягә каршы тору турындагы законнары нигезендә расланган методикасы (алга таба – методика) нигезендә уздырыла.

1.3. Коррупциягә каршы экспертизага кергән актлар (актлар проектлары, эшләнелә торган актлар проектлары) Коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу журналында (алга таба – Журнал) (Әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта) теркәлә.

1.4. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипкә түбәндәгеләрне чагылдыра торган 2 нче кушымта формасы буенча бәяләмә төзелә:

экспертизага бирелгән актның (акт проекты, эшләнелә торган акт проекты исеме) реквизитлары;

экспертиза уздыру өчен нигезләмә;

актта (акт проектында, эшләнелә торган акт проектында) коррупциягә тарту факторлары булуы яки булмавы;

актның (акт проектының, эшләнелә торган акт проектының) коррупциягә тартучы нормаларны үз эченә алган анык нигезләмәләре;

коррупциягә тартуны булдырмас өчен формулировкаларны үзгәртү яки аерым нормаларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр.

2. Министрлык актларына коррупциягә каршы экспертиза

2.1. Министрлык актларына коррупциягә каршы экспертиза норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы яки бүлекнең бүлек башлыгы вазыйфаларын башкаручы башка хезмәткәре (алга таба – җаваплы зат) тарафыннан башкарыла.

2.2. Министрлык актларына коррупциягә каршы экспертиза аларның әлеге актның инициаторы булган структур бүлекчә, Министрлыктагы җаваплы зат яки башка хезмәткәрләр тарафыннан кулланылышына мониторинг уздырган чакта актларда коррупциягә тарту факторлары ачыкланганда, шулай ук актларда коррупциягә тарту факторы булу турында теләсә-нинди ысул белән мәгълүмат алынган чакта уздырыла. Актлар шулай ук экспертиза уздыру өчен Министрлык җитәкчелеге тарафыннан да юлланырга мөмкин.

Үз көчен югалткан дип табылган яки юкка чыгарылган норматив хокукый актларга мөнәсәбәттә коррупциягә каршы экспертиза уздырылмый.

2.3. Актлар коррупциягә тарту факты ачыкланган, тиешле мәгълүмат алынган яки акт Министрлык җитәкчелеге тарафыннан юлланган көнне җаваплы зат тарафыннан Журналга теркәлә.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза акт Журналда теркәлгән көннән соңгы ун көн эчендә уздырыла.

Актның коррпуциягә каршы экспертизасы нәтиҗәләре җаваплы зат тарафыннан әлеге Тәртипнең 1.4 пункты нигезендә төзелә торган бәяләмә белән рәсмиләштерелә һәм Журналда чагылдырыла.

2.5. Бәяләмә, төзелгән һәм имзаланганнан соңгы бер эш көненнән дә соңга калмыйча, җаваплы зат тарафыннан министрның беренче урынбасарына яки аның вазыйфаларын башкаручы затка юллана. Министрның беренче урынбасары (аның вазыйфаларын башкаручы зат) бәяләмәгә виза сала һәм аны министрга яки аның вазыйфаларын башкаручы затка (алга таба – министр) тапшыра.

2.6. Министр актта коррупциягә тартучы факторлар барлыгы турындагы бәяләмә нәтиҗәләре буенча аңа үзгәрешләр кертергә яки аны үз көчен югалткан дип танырга кирәклеге турында карар кабул итә.

2.7. Әлеге акт аның инициативасы буенча төзелгән структур бүлекчә министр тарафыннан әлеге Тәртипнең 2.6 пунктында күрсәтелгән карар

кабул ителгәннән соңгы өч көн эчендә Министрлыкның тиешле акты проектын әзерли һәм аны коррупциягә каршы экспертиза өчен җаваплы затка юллый. Мондый проектка коррупциягә каршы экспертиза әлеге Тәртипнең 3 бүлеге нигезендә уздырыла.

3. Министрлык актлары проектларына, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының Министрлык тарафыннан эшләнелә торган актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза

3.1. Министрлык актларына, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының Министрлык тарафыннан эшләнелә торган норматив хокукый актлары проектларына (алга таба – эшләнелә торган актлар проектлары) коррупциягә каршы экспертиза аларга хокукый экспертиза ясалу белән бер үк вакытта уздырыла.

3.2. Министрлык актлары проектлары һәм эшләнелә торган актлар проектлары коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгына һәм Министрлыкның мондый проектны әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан хокукый экспертиза һәм норма чыгару эшчәнлеге бүлеге башлыгына (алга таба – җаваплы зат) юлланалар.

3.2. Министрлык актлары проектлары һәм эшләнелә торган актлар проектлары (алга таба – проектлар) алар кергән көнне үк җаваплы зат тарафыннан Журналда теркәлә. Коррупциягә каршы экспертиза проект теркәлгәннән соңгы ун көн эчендә уздырыла.

3.3. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре җаваплы зат тарафыннан әлеге Тәртипнең 1.4 пункты нигезендә төзелгән бәяләмә белән рәсмиләштерелә һәм Журналда чагылдырыла. Бәяләмә төзелгән көнендә үк през пректны юллаган структур бүлекчәгә тапшырыла.

3.4. Коррупциягә тарту факторы ачыкланган очракта проектны әзерләгән структур бүлекчә бәяләмәне алганнан соңгы өч көн эчендә проектны дөреслэп эшләп бетерә һәм коррупциягә каршы экспертизаны кабат уздыру өчен аны җаваплы затка юллый. Коррупциягә каршы экспертизаны кабат уздыру дөресләп эшләп бетерелгән проект алынганнан соңгы өч көн эчендә уздырыла.

3.6. Дөресләп эшләп бетерелгән проектта коррупциягә тарту факторы ачыкланмаган очракта җаваплы зат тиешле бәяләмәне проектны коррупциягә каршы экспертизаны кабат уздыру өчен юллаган структур бүлекчәгә җибәрә.

Коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актларны
һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу
журналы

| Актның (акт проектының) экспертизага керү көне | Актны (акт проектын) юллаучы структур бүлекчә | Актның (акт проектының) исеме | Коррупциягә тарту нормалары булу/булмау | Бәяләмә төзелү көне | Искәрмәләр (экспертизаны кабат уздыру турында мәгълүмат, экспертизаны кабат уздыру нәтиҗәләре буенча бәяләмә төзелү көне) (акт проектларына мөнәсәбәттә) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру Тәртибенә 2 нче кушымта

Коррупциягә каршы экспертиза бәяләмәсе

______________________________________________________________________________

(норматив хокукый акт реквизитлары яки норматив хокукый акт проекты исеме)

______________________________________________________________________________

(керү көне)

______________________________________________________________________________

(экспертиза уздырылу көне)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге "Аерым норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" № 883 номерлы карары

____________________________________________________________

(коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен нигезләмә)

<u>Проектта коррупциягә тарту нормаларының булуы яки булмавы:</u>

______________________________________________________________________________

<u>Акт проектының коррупциягә тартучы нормаларны үз эченә алган анык нигезләмәләре :</u>

______________________________________________________________________________

Коррупциягә тартуны булдырмас өчен формулировкаларны үзгәртү яки аерым нормаларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр:

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

Җаваплы зат ____________________ ____________________
(имза) (Ф.И.Ә.и.)